**Г Л А В А**
**Большемашлякского**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
**Республики Татарстан**
422658, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район,
с. Большой Машляк ,
ул. Центральная, дом 20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Зур Мәшләк**
**авыл җирлеге**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**
422658, Татарстан Республикасы,
Зур Мәшләк авылы,
Центральная урамы, 20 нче йорт

Тел.: (84361) 33613, факс: (84361) 33613 , e-mail:BmSl.Rs@tatar.ru

**Постановление** **Карар**

2021 елның 22 декабре Зур Мәшләк авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Югары Мәшләк һәм Бикчурай авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 3 декабрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 4 декабрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Югары Мәшләк авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 4 декабрендә 15 сәг. 00 минутка билгеләргә.

4.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә кирәк.

5.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Югары Мәшләк һәм Бикчурай авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку

йортларына йөреп укучы студентлар, балачактан инвалид, 1 группа инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Бикчурай торак пунктын зират белән тоташтыручы күперне ремонтлау;
- Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай авылларында энергияне саклаучы яктырткычларына хезмәт күрсәтү;
- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү ;
- кышын Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк, Югары Мәшләк, Бикчурай торак пунктларында урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан арындыруга);
- Зур Мәшләк авылының О.Кошевой урамына 150 метр су трубасы сузуга.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕ-МАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ